ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2020 Казан ш. № 393-7/т-2020

2021 елга Түбән Кама шәһәренең «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан тимер юл белән килү юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә 2021 елга Түбән Кама шәһәрендә «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан тимер юл белән килү юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик дәрәҗәдә максималь тариф 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Түбән Кама шәһәренең «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан тимер юл белән килү юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләү турында» 2016 елның 26 августындагы 7-12/т номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.12.2020 № 393-7/т-2020 карарына
кушымта

# Түбән Кама шәһәренең «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан тимер юл белән килү юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф

## I бүлек. Чик дәрәҗәдә максималь тариф

| | Хезмәт күрсәтү төре | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗәдә максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | 1 км ераклыкка йөк алып бару | 1 тонна | 12,89 |

## II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган, әмма «Чик дәрәҗәдә максималь тариф» дигән I бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар яклар килешүендә, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.
2. Йөк ташу һәм төяү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан йөк ташуның факттагы авырлыгы өчен алына.
3. Йөк ташыган өчен түләүне түләттерү ераклыгы төгәл санга кадәр түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге